**СОВЕТ АЮСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**№1** **«20» февраль 2024 ел**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Аю авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»
2023 елның 10 октябрендәге №1 карарына
үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 30 декабрендәге №518-ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары үткәрелүгә бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге Советы

КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлеге Советының 2023 елның 10 октябрендәге №1 «Җир салымы турында» карарының 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 17) пунктчасы белән тулыландырырга:

«17) Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге җирле үзидарә органнары карамагындагы башка җир кишәрлекләренә карата 0,01%».

2.Әлеге карар РФ Салым кодексының 5 статьясы нигезендә законлы көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә торуны үз өстемдә калдырам.

Аю авыл җирлеге башлыгы ____________ А.М.Галимов